**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3984**
**21.06.2024**

Башкарма комитетның 2023 елның 25 августындагы 7766 номерлы Карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Күчемсез милек объектларының аерым төрләренә хокукларны рәсмиләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 3 өлешнең 12 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 25 августындагы 7766 номерлы Карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5.1 пунктының 6 пунктчасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«6) капиталь төзелеш объектының «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнгән техник планы, «Күчемсез милек объектларының аерым төрләренә хокукларны рәсмиләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә дәүләт кадастр исәбе һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәве гамәлгә ашырылмый торган капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшырудан тыш;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов